Приложение к основной образовательной
программе среднего общего образования
средней школы № 15 утверждённой приказом
№ 318 от 28.08.2020г.

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы
«Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»
муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең

**“Этикет- уңышка юл” темасына**

**дәрестән тыш эшчәнлек буенча**

**ЭШ ПРОГРАММАСЫ**

Юнәлеше: гомум-мәдәни тәрбия бирү
Укучыларның яше: 10 сыйныф
Үтәү вакыты: 1 уку елына исәпләнгән

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ
## ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕК ПРОГРАММАСЫН ҮЗЛӘШТЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Әлеге программа түбәндәге универсаль уку гамәлләрен (УУГ) тормышка ашыруны күз алдында тота:

**Шәхси нәтиҗәләр:**

1) шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш һәм аны яхшы өйрәнү теләге булу;
2) әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлый белү;
3) “гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек” төшенчәләрен кабул итү, “башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык”, “кеше кадерен белү” кебек хисләр формалашкан булу.

**Метапредмет (танып-белү, регулятив, коммуникатив) нәтиҗәләр:**

**танып-белү УУГ:**

- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
- классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;
- үрнәк буенча эшли белү;
- аерым темаларга караган сорауларга җавап бирә белү;
- рәсем буенча җөмләләр, сораулар төзи белү;
- аңлап укый белү;
- төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңлаган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү ;
- объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
- укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
- ребуслар, кроссвордлар, шарадалар, анаграммалар һ.б. чишә белү.

**регулятив УУГ:**

- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
- уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;
- уку хезмәтенә бәя бирә белү;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
- укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү;
- дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли белү, алар белән дөрес эш итә белү;
- дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү;

**коммуникатив УУГ:**

- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый һәм аралаша белү күнекмәләрен формалаштыру;
- аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хиселелек, эмпатия хисләре);
- парларда һәм күмәк төркемнәрдә эшли белү;
- әңгәмәдәшең белән контактны башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

**“ЭТИКЕТ – УҢЫШКА ЮЛ” ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕК ПРОГРАММАСЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ**

| **Бүлекләр һәм темалар** | **Оештыру формасы** | **Укучыларның төп эшчәнлек төрләре** |
|---|---|---|
| **1 нче бүлек. Аралашу этикеты (8 сәгать)** | | |
| Җыр белән күңелле. | Аралашу этикасына әңгәмә. | Танып-белү эшчәнлеге |
| Әдәплелек турында. Тәрбияле булуны ничек аңларга? | | |
| Елмаю һәрнәрсәне җылыта. | Укучылар белән әңгәмәләр | Иҗади эшчәнлек |
| Җир йөзендә мәрхәмәтле булып яшәү шатлыгы. | Конференция | Иҗади эшчәнлек |
| Яхшылык эшләү – үзеңне сөендерү | | |
| Башкалар турында уйла. | Викторина | Танып-белү эшчәнлеге |
| «Яхшы сүз, якты көн кебек» мәкале. Тылсымлы сүзләр | Әңгәмә | Танып-белү эшчәнлеге |
| Әйләнә - тирәдәгеләр белән аралашуның этика нормалары. | Әңгәмә | Иҗади эшчәнлек |
| Башка кешедә синң нәрсә ошамый, ул эшне үзең дә эшләмә. | Иҗади проект эшен оештыру (материал җыю) | |
| **2 нче бүлек.Этикет (8 сәгать)** | | |
| Этикет кагыйдәләре. | Этикет кагыйдәләре буенча әңгәмә. | Танып-белү эшчәнлеге |
| Этикет иленә сәяхәт. | Викторина | Иҗади эшчәнлек |
| Без яши торган йорт ,мәктәп. | Конкурс. | Иҗади эшчәнлек |
| Җәмгыять урыннарында үз- үзеңне тоту кагыйдәләре. | Әңгәмә | Иҗади эшчәнлек |

| | | |
|---|---|---|
| Юлларда, транспортта этикет кагыйәләре.<br>Болын, урман, елга – ял итү урыннары.<br><br>Табигатьне саклау турында лозунглар. | Викторина.<br><br><br>Экскурсия. | Иҗади эшчәнлек<br><br>Иҗади һәм танып-белү эшчәнлеге |
| **3 нче бүлек. Янәшәдәгеләр белән аралашу этикасы (9 сәгать)**<br>Башкаларга шатлык бүләк ит.<br><br>Кәеф нәрсәгә бәйле.<br><br>Үз мәрхәмәтлелегегездән оялмагыз.<br><br>Минем өем – минем гаиләм .<br><br>Кеше хезмәттә матурлана.<br><br>Җирдә барыбыз да кояш балалары.<br><br>Газиз кешеләребез- әниләребез.<br><br>Өлкәннәр һәм яшьтәшләр белән.<br>Фотокүргәзмә - «Минем иң яхшы дустым».<br><br>Башкаларның ышанычын акла.<br>Янәшәдәгеләр белән мөгаләмә этикасы. | <br><br>Укучылар белән әңгәмәләр<br><br>Сочинение<br><br>Әңгәмә<br><br>Әңгәмә<br><br>Анкеталар; тестлар<br><br>Конкурс<br><br>Әниләребезне котлыйбыз. Бәйрәм.<br><br>Күргәзмә.<br><br><br>Иҗади проект эшен оештыру (материал җыю) | <br><br>Танып-белү эшчәнлеге<br><br>Иҗади эшчәнлек<br><br>Танып-белү эшчәнлеге<br><br>Танып-белү эшчәнлеге<br><br>Актив фикер йөртү эшчәнлеге<br><br>Хезмәт эшчәнлеге<br><br>Иҗади эшчәнлек<br><br>Иҗади һәм хезмәт эшчәнлеге<br><br><br>Иҗади эшчәнлек |

| | | |
|---|---|---|
| **4 нче бүлек. Коллективта аралашу этикасы (8 сәгать)** | | |
| Барыбыз да бергә җыелгач нинди яхшы. | Әңгәмә | Танып-белү эшчәнлеге |
| Бер-беребезгә киңәш бирәбез. | Әңгәмә | Танып-белү эшчәнлеге |
| Кызлар һәм малайлар өчен махсус һәм гомуми киңәшмә. | Әңгәмә | Танып-белү эшчәнлеге |
| Минем белән кем дә булса сөйләшсә иде. | Табигатьне күзәтү | Танып-белү эшчәнлеге |
| Язгы урман буйлап сәяхәт. | Викторина | Танып-белү һәм иҗади эшчәнлек |
| Этикет- уңышка юл. | Проект | Танып-белү эшчәнлеге. |
| Этикет кагыйдәләре буенча проект. | Әңгәмә | Танып-белү һәм иҗади эшчәнлек |
| Мәрхәмәтлелек кояшка тиң. | Викторина | Танып-белү эшчәнлеге. |
| Йомгаклау дәресе. | Конференция | Танып-белү һәм иҗади эшчәнлек |

## ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

| № | Бүлекләр |
|---|---|
| **1** | **Аралашу этикасы**.<br>Җыр белән күңелле. Тәрбияле булуны ничек аңларга? Елмаю һәрнәрсәне җылыта.<br>Җир йөзендә мәрхәмәтле булып яшәү шатлыгы.<br>Яхшылык эшләү – үзеңне сөендерү. Күргәзмәләр залына читтән торып сәяхәт.<br>Башкалар турында уйла. Яхшылык, кылган яхшылыклар турында әңгәмә «Үзең теләгәнчә эшлә, сиңа карата да шулай эшләсеннәр» кагыйдәсен ачыклау. Төркемнәрдә эш.<br>Башка кешедә сиңа нәрсә ошамый, ул эшне үзең дә эшләмә. Яхшылык кылу һәм тигез хокуклылык турында сөйләшү. Тылсымлы кагыйдәне ятлау: «Башка кешедә сиңа нәрсә ошамый, ул эшне үзең дә эшләмә». |
| **2** | **Этикет** |

| | |
|---|---|
| | Этикет кагыйдәләре буенча.  Культуралы тәртипкә мәсьәләләр чишү. Мәкальләрне аңлату. «Кешене хөрмәт итү – үзеңне хөрмәтләү».<br>Өстәл янына чакыру. Өстәл артында практик дәрес. Без яши торган йорт, мәктәп.<br>Этикет очраклары. Этикет кагыйдәләрен ачыклау.<br>Җәмгыять урыннарында этикет кагыйдәләре.<br>Юлларда, транспортта этикет кагыйдәләре. Юл йөрү кагыйдәләре буенча практик дәрес.<br>Болында, урманда, елга буенда үзеңне тоту кагыйдәләре. |
| **3** | **Әйләнә тирәдәгеләр белән аралашу  этикасы нормалары**<br>Башкага шатлык бүләк ит.<br>Кәеф нәрсәгә бәйле. Яхшы кәеф тудыру кагыйдәләре белән танышу.<br>Үз мәрхәмәтлелегегездән оялмагыз. Газета чыгару.<br>Минем өем – минем гаиләм .<br>Кеше хезмәттә матурлана.  Практик дәрес: «Безнең гомуми йортыбыз».<br>Җирдә барыбыз да кояш балалары.<br>Әниләребезне котлыйбыз. Бәйрәм формасындагы дәрес. Әниләргә концерт.<br>Өлкәннәр һәм яшьтәшләр белән. Фотокүргәзмә - «Минем иң яхшы дустым». «Мин кемне үземнең иң яхшы дустым дип саныйм» темасына әңгәмә. Яхшылык турында киңәш-мәкальләр.<br>Башкаларның ышанычын акла.<br>«Янәшәдәгеләр белән мөгаләмә этикасы» темасына йомгаклау дәресе. |
| **4** | **Коллективта аралашу этикасы**<br>Барыбыз да бергә җыелгач нинди яхшы. “Кәефне ничек күтәреп була?” әңгәмә. Җыр «Чын дус».<br>Бер-беребезгә киңәш бирәбез.<br>Кызлар һәм малайлар өчен махсус һәм гомуми киңәшмә. Сыйныф коллективына таләпләр.<br>Минем белән кем дә булса сөйләшсә иде. Үзеңнең сөйләмеңне төзүгә практик дәрес.<br>Язгы урман буйлап сәяхәт. Урманга экскурсия вакытында урманда үзеңне тоту кагыйдәләре.  Үзеңнең акылыңны, белемеңне, талантыңны бүләк иткәндә коллективыңны уйла. Серле киңәшләр.<br>«Этик грамматикасы” курсының еллык эше турында әңгәмә. |
| **5** | **Кереш, йомгаклау дәресләре** |